# Ял сәгатьләрендә

**Ай календаре**

1 апрель төне йолдызсыз булса, җылы көннәр җитә.
2 апрель көнне көн җылы булып, кошлар туй итсә, ике атна җылы торыр.
3 апрельдә каен суы мул акса, җәй яңгырлы килер. Бу көнне күк күкрәсә, иген уңар.
4 апрельдә ала каргалар су коенса – тиздән җәй җитә.
5 апрельдә кар эреп бетмичә, беренче тапкыр күк күкрәсә, җәй салкын булыр.
6 апрельдә тургай тавыш бирсә – җылыта, кызылтүш җырласа – суыта.
7 апрельдә түбәләрдә кар эремәсә, кырда да тагын бер ай ятачак.
8 апрельдә нинди һава торышы булса, 8 октябрь дә шундый булачак.
9 апрельдә көндезләрен әтәч кычкырмаса, 2-3 көннән явым-төшем булыр.
10 апрельдә кояш кызарып чыгып, тиз арада болытлар аратына качса – яңгырга.
11 апрельдә болытлар өстә булып, тиз йөзсәләр – көннәр матур торыр.
12 апрельдә кыр казлары биектән очса – җәй яңгырлы, түбәннән очса – коры булыр.
13 апрельдә иртәдән вак яңгыр сибәләсә, җәй яңгырлы килер.
14 апрельдә еракта күк күкрәсә, атна-ун көн җылы, аяз булыр.
15 апрельдә елгалар ташып акса, печәнле ел килә.
16 апрельдә елгаларда боз китмәсә, балыкчылар өчен уңышлы ел түгел.
17 апрельдә болытлар өстә булып, тиз йөзсәләр – көннәр матур торыр.
18 апрельдә көндез җылы, төнлә салкынча булса, көннәр утыра.
19 апрельдә җилсез, кояшлы җылы көн була икән – язгы сабан культуралары уңар.
20 апрель төне йолдызлы булса, җиләк һәм гөмбә елы килә.
21 апрель көн кояшлы икән, җәй дә шундый булыр. Көн болытлы булса, җәй дә яңгырлы.
22 апрельдә җил, бәс яки томан күзәтелсә – бар нәрсә дә уңа.
23 апрельдә яшь үрмәкүчләр күрсәгез, җәй ишек төбендә дигән сүз.
24 апрельдә сулар китеп бетмәсә, яз соң килә һәм җәй дә мактанырлык булмый.
25 апрель – таң атканда йолдызлар җемелдәсә, өч көннән яңгыр явар.
26 апрель – бакалар тавыш бирсә, солы чәчәләр.
27 апрель катлы-катлы болытлар тармакланып тарала икән, коры һәм аяз һава торышына ишарә.
28 апрель – берничә көн рәттән көньяктан җил исә икән – яңгырга. Әгәр бал кортлары эш бетереп иртә кайта икән, якын арада җәй җылысы җитәчәк.
29 апрель көнне җил көнбатыштан иссә, яңгырга.
30 апрель – көньяк-көнбатыштан җил исә икән – берничә көнгә сузылган яңгырлар булыр. Әгәр бал кортлары чия куагына кунса, чия уңар.

## “Язгы” салат



Салат өчен:
пекин кәбестәсе, редис, яшел кыяр, пешкән йомырка, майонез, тоз.

Барысын бергә турарга, майонез, тоз салып яхшылап болгатырга. Теләгән кеше киптерелгән икмәк сала ала.

Матурлап табынга бирергә.


**Газетаны оештыручылар һәм редколлегия әгъзалары:** Зарипова Миләүшә Рафис кызы,Закирова Гөлгенә Шәүкәт кызы, Мөхәмәтшина Рәзилә Рәүф кызы.

**Индекс-** 422020

**Адрес:** ТР, Арча муниципаль районы ,Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 2 йорт.





Апрель,2025
№ 4





МБОУ «Ново-Кырлайская СОШ имени Г.Тукая»
МБГБУ «Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта мәктәбе»


# ЧИШМӘ БАШЫ

## 1 нче апрель – көлке көне




1 апрель - Көлке көне. Бу традиция борынгы заманнарда язны каршылау бәйрәме булып саналган, дигән версия бар. Ул көнне кешеләр кышның усал өрәген сурәтләгән карачкыны җирләгәннәр. Аның үлеменә кем гаепле икәнен белмәсен өчен, анда катнашучыларның барсы да битлек кигән. Шуннан бирле 1 апрельдә якыннарны, дусларны алдау, шаярту гадәте кергән. Бу көн юмор, көлү, күңел ачу көненә әйләнгән.
Кайсылары Көлке көне борынгы Римнан таралган дип саный, ул Ахмаклар бәйрәме дип аталган, имеш... Юк, Шаяру көне борынгы Һиндстанда 31 мартта билгеләп үтелгән, диючеләр бар. Франциядә, мәсәлән, 1 апрельне Апрель балыгы дип йөртәләр икән. Германия белән Австриядә 1 апрель элек бәхетсез көн саналган.
1 апрель шаяртулары Россиядә Петр I заманыннан бирле билгеле. Аны патша сараендагы чит ил кешеләре керткән, Көлке көне Петр I күңеленә хуш килгән дип фаразлана.

# Каен бөресе сихәте!

Халык медицинасында каен бөресен элек-электән кулланалар Аның бәвел кудыру, шешенүләргә һәм төрле ялкынсынуларга каршы тору сәләте билгеле. Каен бөресе шулай ук салкын тигәндә, ютәлдән, паразит суалчаннардан килешә.
Гомумән, организмнан агулы матдәләрне чыгарырга, вирусларга каршы көрәшергә булыша. Каен бөресендә байтак микроэлементлар, дубиль матдәләр, эфир мае һәм сумалалар бар. Укучыларыбыз да бу эштән читтә калмадылар. Язгы каникул чорында каен бөресе җыеп, киптерү эше белән шөгыльләнделәр. Һәрбер укучы тиешле норманы үтәп, бөреләрне алып килеп тапшырдылар. Бу акциядә катнашкан барлык укучыларга, эти-әниләргә зур рәхмәт!

**Каен бөресеннән төнәтмә**

Пыяла банкага 10 г чамасы (1 аш кашыгы) каен бөресе, 200 мл (1стакан) кайнап торган су коялар, банканы металл капкач белән каплап, "су мунчасы"нда 15 мин төнәтәләр. Аннан, бер сәгать тирәсе үткәч, сөзеп, кайнар су салып, төнәтмәнең күләмен 200 мл га (бер стакан) кадәр җиткерәләр. Дәвалау 5-7 көн дәвам итә. Төнәтмәне көненә 3 тапкыр ашарга ярты сәгать кала 1-2 әр аш кашыгы эчәләр. һәр дәва чарасын куллану алдыннан табиб белән киңәшләшү зарур!







# 1 апрель - Халыкара кошлар көне

## Конкурста мәктәбебез укучылары

Кошлар жир йөзендә иң күп таралган тереклек ияләре. Жирдә барлыгы 100 миллиард чамасы кош яши. Татарстанда жәй көннәрендә 200ләп, кышын 40 төрдән артык кош очратырга мөмкин. Кошларның иң кечкенәсе колибри, ул берничә грамм авырлыкта гына. Ә иң зурысы тәвә кошы, авырлгы 90 кг га житә. Кошлар табигатьнең күрке.

1 апрель- Халыкара кошлар көне. Бу көн гүзәл табигатебезгә һәм канатлы дусларыбызга хөрмәт тәрбияләү көне буларак та билгеләп үтелә. Бу көнне Иске Иябашбашлангыч мәктәбендә дә « Котә күңел кошларны, аларның шат жырларын » дип исемләнгән тематик сәгать үткәрелде. Әлеге чараның төп максаты-кошларның табигатьтәге һәм кеше тормышындагы күпкырлы әһәмияте, төрләре, аларны саклау турында мәгълумат житкерү. Балалар кошлар турында шигырьләр сөйләделәр, жырладылар, кроссвордлар чиштеләр, мәкаль һәм әйтемнәрне искә алдылар. Кичә ахырында иң матур кош рәсеме ясаучы укучылар билгеләнде.



# 12 апрель -Космонавтика көне

1961 нче елның 12 апрелендә, дөньяда беренче буларак, бортына кеше утырган “Восток” космик корабле җир тирәли орбитага чыгарылды. Бу кеше-очучы космонавт- Юрий Алексеевич Гагарин.

Гагарин космик очышка хәзерлекне космонавтларның беренче группасында башлый. Бик кызу әйләнешле центрифугада сынауларны, авырлыкны югалту очышы тикшерүләрен ул уңышлы утә.

Космоска очуга бар көчен, бөтен вакытын биреп бик нык хәзерләнә. Ару – талуны белми, иптәшләренә булыша, ә иптәшләре аңа ярдәм итәләр. Һәркайсының космоска беренче булып очасы килә. Ләкин барысы да беренче булып Юрий Гагарин очар дип уйлый. Шулай була да. Дәүләт комиссиясе аны билгели.

Юрий, моңарчы һич сыналмаган рейста берүзе очкан вакытта, беренче булып космик трасса ачуны өстенә алуның никадәр җаваплы булуы турында уйлый. Җир йөзендәге барлык кешеләр алдында җаваплылык бит бу. Әмма космостан аның тавышы тыныч яңгырый:

- Очыш әйбәт бара. Мин Җир горизонтын күрәм. Гаҗәеп матур яктылык! – ди ул.

Гагаринның корабле, планетабыз тирәли орбита буенча 108 минутта тулы әйләнеш ясап, уңышлы рәвештә җиргә төште. Космик эра менә шулай башланды.






# Мәктәп тормышы

## Язгы өмәләр башланды

Яз кояшы турырак һәм җылырак карый башлау белән язгы санитар чистарту өмәләре башлана. Чөнки яз җитү белән кыш буе кар астында күренми яткан чүп-чар баш калкыта башлый. Кыштан соң табигать уяна, тирә-якны тәртипкә китерү, төзекләндерү вакыты җитә. Район күләмендәге өмәдән безнең мәктәп укучылары да читтә калмады. Күмәк эш – беткән эш, диләр. Бергәләшеп көч куйганда, тиз генә башлаганны төгәлләп була. Бергәләп башкарган хезмәтнең нәтиҗәсе дә күзгә күренерлек матур булды. Бергәләшеп күңелле итеп җыештырганнан соң, тирә-юнебез тагын да күркәмләнеп, ямьләнеп калды. Яшәгән җиребезне чиста тоту – һәркемнең изге бурычы. Әйләнә-тирәбездәге чисталык һәм матурлыкны булдыру һәм саклау бары тик үзебезнең кулларда икәнен онытмыйк, дуслар!







# Иҗат чишмәсе



***Сугыш чоры баласы, ветеран укытучыбыз Галяветдинова Венера Рәфгать кызы иҗаты***

**Китмибез**

(Тукайга ияреп)

Китмибез без, ник китик соң
Кесәдә юк миллион.
Анда да шул, монда да шул
Һәркайда бар шпион.

Китмибез булгач ,китмибез,
Йөрмибез эзләп рәхәт.
Артыннан ияреп йөри
Син күрәсе ул михнәт.

Монда тудык ,монда үстек
Мондадыр безнең әҗәл.
Туда-сюда чыгып китеп
Кайта алмаучылар бигрәк җәл.

Без юләрме? Илдән китсәк,
Рәхәт кайсы дөньяда?
Лучше булса китегез сез
Туда сами господа!

Хөр мәмләкәт – хөр Русия!
Без бит сиңа бирекkән.
Безнең Ватан җирдә – үрнәк,
Тынычлыкка көчле терәк.



**Безнең Тукай**

Туган көнең нинди матур,
Кырлайда зур тантана .
Нәни Апушны сагынып,
Килә дуслар кунакка.

Килә төрек , әзербайҗан
Килә Мәскәү һәм Казан.
Авылыбызны яңгыратып,
Ишетелә моңлы азан.

Гаскәр кеби тезелеп тора,
Без утырткан каеннар.
Күлләрендә чумып уйный
Зифа матур аккошлар.

Тукай,синең чишмәкәйнең
Суы һаман кипмәгән.
Бардыр әле тагын берәү
Тәмле суын эчмәгән.

Күрсә иде бу хозурны,
Хәйләкәр таз малаең.
Кәҗә белән сарык асрап,
Гомер иткән агаең.

Һәркем өчен якын хәзер
Тукайның Казан арты
Аңа мәдхия җырлыйлар
Барлык илебез халкы.



# Мәктәп тормышы

Сталинград сугышында немец-фашист гаскәрләрен совет гаскәрләре тар-мар иткән көн алдыннан мәктәбебездә «Җиңү юллары»дигән виртуаль экскурсия үткәрелде. Аны тәрбия эше буенча директор киңәшчесе И.М. Шакирова алып барды.

Чара башында яшь армиячеләр, Җиңү волонтерлары егетләре Сталинград сугышы барышы белән таныштырдылар. Чара барышында укучылар Бөек Ватан сугышы елларында халкыбызның батырлыгы һәм ныклыгы символына әверелгән «Сталинград сугышы» музей-панорамасы һәм Мамай курганы кебек әһәмиятле урыннарда булдылар. Сталинград өчен сугыш Бөек Ватан сугышының борылыш мизгелләренең берсе булды һәм Россия тарихында төп рольне уйнады. Мамай Курганы, истәлекле урын буларак, Ватан өчен көрәшкән совет солдатларының батырлыгын һәм каһарманлыгын гәүдәләндерә. Экскурсиядә катнашучылар Сталинград оборонасы тарихы һәм Кызыл Армия солдатларының батырлыклары белән танышып, героик үткәннәр атмосферасына чуму өчен уникаль мөмкинлек алдылар. Мамай Курганы-һәйкәл генә түгел, батырлык һәм ныклык символы да. Виртуаль сәяхәт вакытында укучылар " Ватан-Ана чакыра!"һәм мемориалның башка элементларының шәһәрне саклаучыларның батырлыгы турындагы истәлекне мәңгеләштерүдә зур роль уйнавын аңладылар. Экскурсия җанлы кайтаваз уятты, герой-шәһәр Волгоград тарихы белән кызыксынуны үстерүгә һәм патриотизм тәрбияләүгә ярдәм итте.





